ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2013, № 1, № 5; 2014, № 4, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 4, № 12 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктында:
а) түбәндәге эчтәлекле яңа тугызынчы абзац өстәргә:
«уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга;»;
б) тугызынчы – унөченче абзацларны тәңгәл рәвештә унынчы – ундүртенче абзацлар дип санарга;

2) 8 статьяда:
а) исемендә «ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга» сүзләреннән соң «, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;
б) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2. Төп уку-укыту программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмдә һәм тәртиптә транспортта йөргән өчен субсидия бирелә.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Ятим балаларга, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга һәм ятим балалар, ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга түбәндәгеләр бирелә:

югары белем бирү мәгариф оешмаларының әзерлек бүлекләрендә түләүсез уку;

көндезге уку рәвешендә квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү программасы буенча икенче урта һөнәри белемне түләүсез алу;

квалификацияле эшчеләр әзерләү программасы буенча түләүсез беренче һәм икенче урта һөнәри белем алу;

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә бер мәртәбә белем алу.

Урта гомуми белем бирү уку-укыту программаларын, урта һөнәри белем бирү уку-укыту программаларын үзләштерү кысаларында һөнәри белем алган ятим балаларның һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларның Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә бер мәртәбә белем алу хокукы саклана.»;

г) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән укып һәм тәрбияләнеп, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар өчен оешмаларны, ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбияләү учреждениеләрен тәмамлаучылар, Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә төп һөнәри уку-укыту программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә укып белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны тәмамлаучылар – ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затлар, Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә төп һөнәри уку-укыту программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары нигезендә укуын дәвам итүче затлардан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән күләмдә һәм тәртиптә түләүсез кием-салым, аяк киеме комплекты, йомшак инвентарь, җиһазлар һәм бер мәртәбә бирелә торган акчалата пособие белән тәэмин ителәләр.

Әгәр социаль ярдәмнең өстәмә гарантияләре ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга алар элек белем алган һәм (яисә) тәрбияләнгән оешма акчалары исәбеннән бирелгән булса, аларга әлеге пунктта каралган гарантияләр бирелми.»;

д) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджеты яисә җирле бюджетлар акчалары исәбеннән көндезге уку рәвешендә төп һөнәри уку-укыту программалары буенча белем алучы ятим балаларга һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм калган балалар арасыннан булган затларга, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга тулы дәүләт тәэминаты белән беррәттән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә социаль ярдәмнең түбәндәге чаралары күрсәтелә:

айлык стипендия бирелә, аның күләме әлеге мәгариф оешмасында белем алучылар өчен билгеләнгән стипендия күләме белән чагыштырганда кимендә илле процентка арттырыла;

өч айлык дәүләт социаль стипендиясе күләмендә уку әдәбияты һәм язма әсбаплар сатып алуга еллык пособие бирелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2016 елның 12 декабре
№ 96-ТРЗ